Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районының Татар Тау Иле авыл җирлеге

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлеге
Татар Тау Иле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
**КАРАР**

6 декабрь, 2019 ел № 2

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Татар Тау Иле авыл җирлегенең Татар Тау Иле торак пунктында 2019 елның 6 декабрендәге гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә авыл җирлегендә яшәүчеләр белән очрашу беркетмәсе нигезендә:

- җыенны уздыру өчен билгеләнгән территориядә яшәүче һәм халык җыенында катнашырга хокуклы гражданнар саны 437 (дүрт йөз утыз җиде).
- халык җыены эшендә катнашкан гражданнар саны 223 (ике йөз егерме өч).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**РИЗА**» өчен гомуми сан 219 (ике йөз унтугыз).
- гражданнар җыенына кертелгән мәсьәләгә «**КАРШЫ**» өчен гомуми сан 4 (дүрт).

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып түбәндәге карар кабул ителде:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» гы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25 статьясындагы 6 өлеше нигезендә **гражданнар җыены мәсьәләсе буенча карарын**, түбәндәге мәсьәлә буенча «Сез 2020 елда Питрәч муниципаль Татар Тау Иле авыл җирлегенең Татар Тау Иле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 1 төркем инвалидларыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасы студентлары һәм мәктәп укучыларыннан, 80 яшькә җиткән гражданнардан тыш үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау»

**кабул ителгән дип санарга.**

2. Әлеге карарны «Вперёд» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) һәм Татар Тау Иле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында да бастырып чыгарырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (халыкка игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

Татар Тау Иле авыл җирлеге башлыгы Г.Н. Шаров